| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>ЧЕРЕМШАНСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>**СОВЕТ ИВАШКИНСКОГО**<br>**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**<br><br>ул.Центральная, д.39, с.Ивашкино, 423113 | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>**ИВАШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**<br>**СОВЕТЫ**<br><br>Үзек урамы, 39 йорт, Ивашкино авылы, 423113 |

тел./факс (84396) 3-82-19 email: Iva.Cmn2@tatar.ru

**05 март 2025 ел** **№ 151**

# Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ивашкино авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 18 февралендәге № 118 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ивашкино авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 18 февралендәге 118 номерлы карарына (Советның 11.06.2019 ел, № 130, 30.09.2021 ел, № 41, 23.08.2024 ел, № 128, 26.12.2024 ел, № 146 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның 14 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «Салым ташламасы бирелә торган сайланган салым салу объектлары турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан салым органына үз теләге белән күрсәтелгән объектларга карата салым ташламасы кулланыла торган салым чоры булган елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча тапшырыла. Сайланган салым салу объектлары турында хәбәрнамә салым органына дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырылырга мөмкин».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Ивашкино авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Ф.П. Андреев